| | |
|---|---|
| **ГЛАВА БОЛЬШЕРУСАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ УРСАК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022елның 10 ноябрь Олы Урсак авылы № 4

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең Бушанча авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлеге Уставының 22 статьясына туры китереп КАРАР КЫЛА:

1.2022 елның 24 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Бушанча авылы, Совет урамы, 32 нче йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең Бушанча авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2023 елда Татарстан РеспубликасыКайбычмуниципаль районы Олы Урсакавылҗирлегетерриториясендәяшәүурыныбуенчатеркәлгәнһәмдаимияшәүчебалигъбулганһәркешедән 500 (биш йөз) сумкүләмендәүзарасалымкертүһәмалынганакчаларнытүбәндәгеэшләрнебашкарубуенчаҗирлеәһәмияткәиямәсьәләләрнехәлитүгәюнәлдерүбеләнкилешәсезме?:

- урамдагы яктырткычларны ремонтлау,моның өчен материаллар сатып алу
- сuүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл җирлеге  чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- Бушанча авылы зиратын чистарту һәм төзекләндерү;
-санкцияләнгән һәм санкцияләнмәгән чүплекләр территорияләрен чистарту;

« ӨЧЕН»                                        «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Олы Урсак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга .http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлеге башлыгы                    Зиннәтуллин  Г.А.